**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 16 май № 345

г. Казань

«Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру турында» 2015 ел, 16 март, ТРЗ-12 нче Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча чаралар хакында

«Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 ел, 28 июнь, ФЗ-172 нче Федераль закон нигезендә, «Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру хакында» 2015 ел, 16 март, ТРЗ-12 нче Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) раслаларга:

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый үсеш стратегиясен эшләү, корректировкалау, иҗтимагый фикер алышу, мониторинглау һәм гамәлгә ашыруны тикшерүдә тоту тәртибен;

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру чаралары планын эшләү, корректировкалау, иҗтимагый фикер алышу, мониторинглау һәм гамәлгә ашыруны тикшерүдә тоту тәртибен;

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый үсеш фаразларын эшләү, корректировкалау, иҗтимагый фикер алышу, мониторинглау һәм гамәлгә ашыруны тикшерүдә тоту тәртибен.

2. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгын Татарстан Республикасында стратегик планлаштыру өлкәсендә вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\345.docx